БОЕРЫК

17.10.2016 № 892 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2015 ел, 11 март, 241 од номерлы боерыгының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

БОЕРАМ:

«Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү буенча коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2015 ел, 11 март, 241 од номерлы боерыгының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4 пункт. Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү буенча коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу тәртибен (алга таба – Тәртип) түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Үз карары белән әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта итеп китерелгән форма буенча төзелгән һәм субсидия бирү шарты булып торган Килешүгә кертелгән субсидияләрне куллану нәтиҗәлелеге билгеләмәләрен билгеләү.»;

4.6 пунктта «әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта белән расланган» сүз тәртибен «әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелгән» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

Тәртипне түбәндәге эчтәлекле 5 нче бүлек белән тулыландырырга:

«5. Субсидияләрне кайтару тәртибе

5.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Мәдәният өлкәсендәге иҗади проектларны тормышка ашыру өчен чыгымнарны каплау максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында" 2014 ел, 12 май, 314 нче карары белән билгеләнгән очракларда субсидияләр аларны алучылар тарафыннан һәм карарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш;

2.3 пункт. Әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - Россия Федерациясенең Бюджет кодексы белән билгеләнгән очраклардан тыш, субсидия хисабына чит ил валютасы алу тыелуын истә тотарга.».

Министр А.М.Сибагатуллин